**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 ноябрендәге 4904 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 2 ноябрендәге 4500 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре балансында торучы муниципаль милекне (төп чараларны), шулай ук Казан шәһәренең муниципаль милек казнасын тәшкил итә торган милекне исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Казан шәһәренең муниципаль милкен (төп чараларын) юкка чыгару процессын оптимальләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 2 ноябрендәге 4500 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре балансында торучы муниципаль милекне (төп чараларны), шулай ук Казан шәһәренең муниципаль милек казнасын тәшкил итә торган милекне исәптән төшерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 15 октябрендәге 5261 номерлы, 2021 елның 11 маендагы 1155 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«4) яңа капиталь төзелеш объектын төзү»;

1.2. 3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«3.2.9. Яңа капиталь төзелеш объектын төзүгә бәйле рәвештә объектны исәптән төшергәндә, дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органының һәм (яки) җирле үзидарә органының тиешле карарының күчермәсе һәм яңа төзелеш башлау максатыннан күчемсез милек объектын сүтүне күздә тота торган проект документациясеннән өземтә бирелә».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**